**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"6" ноябрь 2020 ел № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1,56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Түбән Бәрәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел №116 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең Түбән Бәрәскә торак пунктында этаплы халык җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә авылы территориясендә 2021 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең Түбән Бәрәскә авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Территорияне төзекләндерү һәм чистарту:

- агач һәм куакларны кисү, үсентеләрне чистарту, чүп-чар материалларны каты көнкүреш калдыклары полигонына кадәр илтү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, транспорт хезмәте күрсәтү, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү (лампочкаларны, үткәргечләрне ремонтлау, алыштыру) һәм лампочкалар сатып алу;

- Культурная урамындагы басманы ремонтлау өчен материал сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

- авыл территориясен яшелләндерү (Чишмәле ур.);

- үлән чабу өчен ваклаучы чапкыч сатып алу;

- Түбән Бәрәскә авыл җирлеге территориясенә кергәндә аншлаг (композиция) урнаштыру;

- юл билгеләрен сатып алу һәм урнаштыру;

2) Күмү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:

- зират территориясен чистарту, агач һәм куакларны, үсентеләрне кисү, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.

3) Паркны төзекләндерү:

- парк территориясен чистарту, транспорт хезмәте, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

- күлне төзекләндерү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең Түбән Бәрәскә авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын

Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы: Фатыхова А.В.